**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 гыйнварындагы 175 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 8 октябрендәге 3650 номерлы «Торак пунктлар өстендә авиация эшләрен, парашют белән сикерүләрне, һава судноларының күрсәтмә очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын башкаруга, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрүгә, шулай ук торак пунктлар чикләрендә урнашкан һәм алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә) рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карары нигезендә, Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2024 елның 28 ноябрендәге 69/15/3471 номерлы хаты нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 8 октябрендәге 3650 номерлы «Казан шәһәре территориясе өстендә авиация эшләрен, парашют белән сикерүләрне, һава судноларының күрсәтмә очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын башкаруга, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрүгә, Казан шәһәре чикләрендә урнашкан һәм алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә) рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына

(аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 28 мартындагы 1156 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге 4033 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 2931 номерлы, 2020 елның 26 июнендәге 1749 номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге 3250 номерлы, 2022 елның 27 июлендәге 2410 номерлы, 2023 елның 2 маендагы 1237, 2024 елның 15 ноябрендәге 4709 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар кушымтасының 2.5.1 пунктындагы 14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«14) Россия Федерациясе Кораллы көчләренең Генераль штабы рөхсәте нигезендә башкарыла торган аэротөшерү эшләрен ПАРО-90[2] өстәмәләре һәм СТГМ-90[3] инструкциясе таләпләре нигезендә башкару мөмкинлеге турында Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан килештерү»;

1.2. карар кушымтасының 2.6.1 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«4) Россия Федерациясе Кораллы көчләренең Генераль штабы рөхсәте нигезендә башкарыла торган аэротөшерү эшләрен ПАРО-90[2] өстәмәләре һәм СТГМ-90[3] инструкциясе таләпләре нигезендә башкару мөмкинлеге турында Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан килештерү».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**